# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 18 ноябрендә 09.00 сәгатьтә үткәрелгән «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе тозелде:

- Иске Имән торак пунктнының авыл эчендәге Мулланур Вахитов, Нәҗип Вахитов урамы юлларын ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).
- Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
- Иске Имән торак пунктының Каратал урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру ( килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Имән торак пункты юлларын грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Иске Имән торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;
- Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу».

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 173 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 126 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 126 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге территориясендә Иске Имән авылында I төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Иске Имән торак пунктнының авыл эчендәге Мулланур Вахитов, Нәҗип Вахитов урамы юлларын ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

- Иске Имән торак пунктының Каратал урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру ( килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Имән торак пункты юлларын грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Иске Имән торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

- Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;

- Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче — Р.Ә.Исламова